**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 9 июнь № 378

г. Казань

Бүлмәләрнең милекчеләре исеменнән эш итәргә вәкаләтле затлар катнашында күпфатирлы йортта гомуми мөлкәтне капиталь ремонт буенча башкарылган эшләрне һәм (яки) күрсәтелгән хезмәтләрне кабул итү тәртибен билгеләү турында

«Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны оештыру турында» 2013 елның 25 июнендәге 52-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 3 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Теркәлгән Бүлмәләрнең милекчеләре исеменнән эш итәргә вәкаләтле затлар катнашында күпфатирлы йортта гомуми мөлкәтне капиталь ремонт буенча башкарылган эшләрне һәм (яки) күрсәтелгән хезмәтләрне кабул итү тәртибен расларга.

2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Төзелеш, транспорт, торак-коммуналь һәм юл хуҗалыклары идарәсенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 9 июнь, 378 нче карары белән расланды

Бүлмәләрнең милекчеләре исеменнән эш итәргә вәкаләтле затлар катнашында күпфатирлы йортта гомуми мөлкәтне капиталь ремонт буенча башкарылган эшләрне һәм (яки) күрсәтелгән хезмәтләрне кабул итү тәртибе

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Бу Бүлмәләрнең милекчеләре исеменнән эш итәргә вәкаләтле затлар катнашында күпфатирлы йортта гомуми мөлкәтне капиталь ремонт буенча башкарылган эшләрне һәм (яки) күрсәтелгән хезмәтләрне кабул итү тәртибе (алга таба – Тәртип) Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәтне капиталь ремонтлау төбәк программасы һәм, күпфатирлы йортлардагы бүлмәләр милекчеләре тарафыннан сайланган күпфатирлы йортта гомуми мөлкәтне капиталь ремонтлау фондын формалаштыру ысулына бәйсез рәвештә, аны тормышка ашыруның кыска вакытлы планнары нигезендә күпфатирлы йортта гомуми мөлкәтне капиталь ремонтлау буенча башкарылган эшләрне һәм (яки) күрсәтелгән хезмәтләрне кабул итүнең гомуми кагыйдәләрен (алга таба – капиталь ремонтлау буенча эшләрне кабул итү) билгели, шулай ук капиталь ремонтлау буенча эшләрне кабул итү комиссиясен (алга таба – комиссия) төзү һәм аның эшләү һәм капиталь ремонтлау буенча эшләрне кабул иткәндә барлыкка килә торган каршылыкларны җайга салу тәртибен регламентлаштыра.

1.2. Капиталь ремонтлау буенча эшләрне кабул итү Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, Россия Федерациясе Гражданнар кодексы, Россия Федерациясе Торак кодексы, «Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны оештыру турында» 2013 елның 25 июнендәге 52-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (алга таба – Татарстан Республикасы Законы), Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасының бүтән норматив хокукый актлары һәм әлеге Тәртип нигезендә, шулай ук гамәлдәге ведомство төзелеш нормалары һәм күпфатирлы йортта гомуми мөлкәтне капиталь ремонтлау буенча хезмәтләр күрсәтүгә һәм (яки) эшләр башкаруга шартнамә (алга таба – шартнамә) нормалары һәм шартлары нигезендә гамәлгә ашырыла.

1.3. Әлеге Тәртип нигезендә капиталь ремонтлау буенча эшләрне кабул итү Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты раслаган Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәтне капиталь ремонтлау төбәк программасын тормышка ашыруның кыска вакытлы планына кертелгән күпфатирлы йортларга карата башкарыла.

## 2. Комиссия төзү һәм эшләү тәртибе

2.1. Капиталь ремонтлау буенча эшләрне кабул итүне түбәндәгеләр оештыра:

бүлмәләре милекчеләре төбәк операторы счетында, счетларында капиталь ремонтлау фондларын формалаштырган күпфатирлы йортларда – төбәк операторы белән төзелгән шартнамә нигезендә техник заказчы функцияләре тапшырылган затлар (алга таба – Техник заказчы);

бүлмәләре милекчеләре махсус счетта капиталь ремонтлау фондларын формалаштырган күпфатирлы йортларда – махсус счет иясе.

2.2. Комиссия составы Техник заказчы яки махсус счет иясе тарафыннан, күпфатирлы йорттагы бүлмә милекчеләре сайлаган күпфатирлы йортта гомуми мөлкәтне капиталь ремонтлау фондын формалаштыру ысулын исәпкә алып, раслана. Комиссия рәисе итеп Техник заказчы яки махсус счет иясе вәкилләре арасыннан билгеләнә. Комиссия рәисе комиссия эшен, комиссия әгъзалары утырышларын әзерләүне оештыра.

2.3. Комиссия составына мәҗбүри тәртиптә түбәндәгеләр кертелә:

бүлмәләре милекчеләре төбәк операторы счетында, счетларында капиталь ремонтлау фондларын формалаштырган күпфатирлы йортларда капиталь ремонтлау буенча эшләрне кабул иткәндә – төбәк операторы, күпфатирлы йортта гомуми мөлкәтне капиталь ремонтлау үткәрүне гамәлгә ашырган оешмалар вәкилләре (алга таба – подрядчы), Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы, Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең республика дәүләт торак күзәтчелеге вазыйфаларын башкаручы башкарма органы, җирле үзидарә органы, төбәк операторы белән төзелгән төзелеш контролен гамәлгә ашыру шартнамәсе нигезендә төзелеш контролен гамәлгә ашыручы оешмалар вәкилләре, күпфатирлы йорт белән идарәне гамәлгә ашыручы затлар һәм күпфатирлы йорттагы бүлмәләрнең барлык милекчеләре исеменнән капиталь ремонтлау буенча күрсәтелгән хезмәтләрне һәм (яки) башкарылган эшләрне кабул итәргә, шул исәптән тиешле актларны имзаларга вәкаләтле зат;

бүлмәләре милекчеләре махсус счетта капиталь ремонтлау фондларын формалаштырган күпфатирлы йортларда капиталь ремонтлау буенча эшләрне кабул иткәндә – махсус счет иясе, подрядчы, Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы, Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең республика дәүләт торак күзәтчелеге вазыйфаларын башкаручы башкарма органы, төзелеш контролен гамәлгә ашыру шартнамәсе нигезендә төзелеш контролен гамәлгә ашыручы оешмалар вәкилләре һәм күпфатирлы йорттагы бүлмәләрнең барлык милекчеләре исеменнән капиталь ремонтлау буенча күрсәтелгән хезмәтләрне һәм (яки) башкарылган эшләрне кабул итәргә, шул исәптән тиешле актларны имзаларга вәкаләтле зат.

2.4. Махсуслашкан оешмалар җәлеп ителеп эксплуатацияләнә торган лифт яки бүтән җайланмаларны капиталь ремонтлау буенча эшләрне кабул иткәндә комиссия составына әлеге оешмалар вәкилләре кертелә.

## 3. Капиталь ремонтлау буенча эшләрне кабул итүне оештыру

3.1. Капиталь ремонтлау буенча эшләрне кабул итү шартнамә яклары имзалаган һәм җирле үзидарә органы, Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең республика дәүләт торак күзәтчелеге вазыйфаларын башкаручы башкарма органы,

төбәк операторы белән төзелгән төзелеш контролен гамәлгә ашыру шартнамәсе нигезендә төзелеш контролен гамәлгә ашыру шартнамәсе нигезендә төзелеш контролен гамәлгә ашыручы оешма, күпфатирлы йорт белән идарәне гамәлгә ашыручы затлар, шулай ук әгәр күпфатирлы йортта гомуми мөлкәтне капиталь ремонтлау бу күпфатирлы йорттагы бүлмәләрнең милекчеләре карары нигезендә башкарылган очракта, күпфатирлы йорттагы бүлмәләрнең барлык милекчеләре исеменнән эш итәргә вәкаләтле зат белән килештерелгән беренчел исәп документларының № КС-2 бердәм нормага китерелгән формасы буенча күрсәтелгән хезмәтләрне һәм (яки) башкарылган эшләрне кабул итү актлары, шулай ук беренчел исәп документларының № КС-3 бердәм нормага китерелгән форма буенча башкарылган эшләр һәм чыгымнар хакы турында белешмәләр нигезендә башкарыла.

3.2. Беренчел исәп документларының № КС-2, № КС-3 бердәм нормага китерелгән формалары буенча капиталь ремонтлау эшләрен кабул итү төзелгән шартнамәләрдә каралган шартларга һәм вакытларга ярашлы рәвештә гамәлгә ашырыла.

3.3. Күрсәтелгән хезмәтләрне һәм (яки) башкарылган эшләрне кабул итү акты капиталь ремонтлау буенча башкарылган эшләр өчен акчаны шартнамәдә каралган тәртиптә һәм вакытларда төбәк операторы яки махсус счет иясе тарафыннан күчерү өчен нигез булып тора (Россия Федерациясе Торак кодексының 190 статьясындагы 3 өлештә күрсәтелгән очрактан тыш).

3.4. Капиталь ремонтлау буенча эшләр тулысынча тәмамланырга 10 эш көне кала подрядчы язма рәвештә Техник заказчыга һәм махсус счет иясенә эшләрнең тулы күләмдә тәмамлануы һәм капиталь ремонтлау буенча эшләрне кабул итү кирәклеге турында хәбәр итә.

3.5. Капиталь ремонтлау буенча эшләрнең кабул итүгә әзер булуы турында подрядчының язмача хәбәре нигезендә комиссия рәисе әлеге хәбәрне алган көннән соң өч эш көне эчендә күпфатирлы йортны капиталь ремонтлау буенча эшләрне кабул итү урынын һәм вакытын билгели һәм кабул итү датасына кимендә җиде эш көне кала комиссия әгъзаларына җиткерә.

3.6. Күпфатирлы йортны капиталь ремонтлау буенча эшләрне кабул итү комиссия тарафыннан башкарылган эшләрнең шартнамә шартларына туры килүе нигезендә гамәлгә ашырыла. Кабул иткәндә комиссия Капиталь ремонты тәмамланган торак биналарны ВСН 42-85(р) кулланылышка кабул итү кагыйдәләре (СССР Дәүләт граждан төзелешенең 1985 ел, 7 май, 135 нче боерыгы белән расланган, 1997 ел, 6 май редакциясендә), техник һәм смета документлары һәм объектларны карап тикшерү һәм аларны кабул итүне җайга сала торган бүтән документлар белән эш итә, әгәр Россия Федерациясе Торак кодексы, Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары һәм бүтән норматив хокукый актлары белән бүтәне каралмаса. Аерым корылмалар, кисәкләр һәм җайланмаларның эшкә яраклылыгын комиссия сынаулар үткәрү юлы белән тикшерә.

3.7. Техник заказчы яки махсус счет иясе капиталь ремонтлау буенча эшләрне кабул итүдә катнашучы комиссия әгъзалары таләбе буенча аларга күпфатирлы

йортны капиталь ремонтлау буенча эшләрне кабул итү башланганчы капиталь ремонтлауга башкарма һәм техник документлар белән танышуны тәэмин итә.

3.8. Күпфатирлы йортны капиталь ремонтлау буенча эшләрне кабул итү күпфатирлы йортны капиталь ремонтлау буенча эшләрне кабул итү буенча комиссия актлары (алга таба – кабул итү акты) нигезендә гамәлгә ашырыла, ул әлеге Тәртипкә кушымтага ярашлы форма буенча төзелә һәм әлеге Тәртипнең 2.3 пунктында күрсәтелгән затлар белән килештерелә.

3.9. Комиссия әгъзалары искәрмәләр яки тәкъдимнәр күрсәтеп, үзләренең аерым фикерләрен белдерә ала, алар кабул итү актына теркәлә. Күпфатирлы йортны капиталь ремонтлау буенча эшләрне кабул итүгә комиссия әгъзаларының берсе каршы килсә, алар урында барлык комиссия әгъзалары тарафыннан карап тикшерелә һәм күпфатирлы йортны капиталь ремонтлау буенча эшләрне кабул итү мөмкинлеге яки мондый кабул итүдән баш тарту турында карар кабул ителә.

3.10. Комиссия капиталь ремонтлау буенча эшләрне кабул итүдән баш тарту турында карар кабул иткән очракта Техник заказчы яки махсус счет иясе өч көн эчендә нигезле кире кагу бәяләмәсе төзи, ул комиссия әгъзалары тарафыннан имзалана һәм имза куелган көннән соң бер эш көне эчендә подрядчыга җибәрелә.

3.11. Кабул итү актын имзалаган көннән соң 10 көн эчендә төбәк операторы яисә Техник заказчы (төбәк операторы тарафыннан Техник заказчы функцияләрен шартнамә нигезендә тапшырган очракта) тиешле күпфатирлы йорт идарәсен гамәлгә ашыручы затка күпфатирлы йортта гомуми мөлкәтне капиталь ремонтлау үткәрү турында документлар күчермәләрен (шул исәптән проект, смета документлары, капиталь ремонтлау буенча хезмәтләр күрсәтү турында һәм (яки) эшләр башкару турында шартнамәләр, күрсәтелгән хезмәтләрне һәм (яки) башкарылган эшләрне кабул итү актлары күчермәләре) һәм капиталь ремонтлау үткәрү белән бәйле бүтән документларны, финанс документларыннан тыш, тапшыра.

3.12. Комиссия кабул иткән карарларга законнар нигезендә суд тәртибендә шикаять белдерелергә мөмкин.